Татарстан Республикасы
Әлмәтмуниципаль районы
Яңа Никольский авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ № 2

14 май 2020 ел

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авылы башкарма комитетының 2015 елның 20 ноябрендәге 19 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче затның, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесенең үз керемнәре, мөлкәте, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру кагыйдәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 нче статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыи Яңа Никольский авыл җирлеге Уставы нигезендә

Яңа Никольский авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авылы башкарма комитетының 2015 елның 20 ноябрендәге 19 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче затның, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесенең үз керемнәре, мөлкәте, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру кагыйдәләре турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-3 пунктта «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Новоникольск авылы, Үзәк урам, 100 нче йорт; Салкын Алан авылы, Луговая урамы, 60 нчы йорт; Иштирәк авылы, Чишмә урамы, 3 нче йорт; Хазовка, Болтаево, Завод, Кәминкә, Кече Шуган, Поташная Поляна, Сосновка,территоиясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты “Интернет” челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Никольский авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Х.Х. Дәүләтгәрәев